ГЛАВА
ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Колхозная, дом 1,
село Шланга, 422474

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Колхоз урамы, 1нче йорт,
Шланга авылы, 422474

Тел.: (84375) 3-91-36, 8(9377754063), факс: (84375) 3-91-36, e-mail: Shlang.Drz@tatar.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 18 ноябре №14

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегенең Шланга авылында, гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советынын 10.10.2009 ел, № 44/1 (15.11.2019 ел, № 45/7 редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә **карар** бирәм:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегенең Шланга авылында, гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2021 елның 1 декабрენә 15:00 сәгатьтә үткәрүне Шланга авыл мәдәният йортында, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Шланга авылы, Ленин урамы, 22а йорт, адресы буенча билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“2022 елда үзара салым кертүгә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авылы, Шланга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме?:

- Шланга авылының Совет, Фрунзе, Киров гамәлдәге урамнары буенча юлларга вак таш салу;

- Шланга авылының К. Маркс урамында юл-урам челтәрен ремонтлау;

- Ленин урамы 22 а йорт номеры буенча урнашкан, Шланга авылы мәдәният йорты янындагы коены ремонтлау

“ӘЙЕ” “КАРШЫ” ”.

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районының Шланга авыл җирлеге башлыгы И.И. Якупов